Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш  авыл җирлеге Советы

**КАРАР № XXXIV-2**

Котлы Бөкәш  авылы                                                         2017 елның 27 сентябре

Котлы Бөкәш  авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләмен һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын индексацияләү турында

«Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык вазыйфаи эш хаклары күләмнәрен индексацияләү турында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 июлендәге 525 номерлы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының « Котлы Бөкәш  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2017 елның 1 октябреннән 1,049 тапкыр арттырырга (индексацияләргә):

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге Советының  2016 елның 8 сентябрендәге 15 номерлы  “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авылҗирлеге җирле үзидарә органнарында даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләүче затларга муниципаль вазыйфадан пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибе турында”гы карары белән расланган  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге Башлыгының акчалата бүләкләүне;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге Советының  2016 елның 09 сентябрендәге XVI номерлы  “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш  авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык һәм башка өстәмә түләүләр күләмнәрен һәм

аларны гамәлгә ашыру тәртибен билгеләү турында” гы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладларын;

2. Билгеләргә:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән хезмәткәрләрнең акчалата бүләкләү һәм вазыйфаи окладлары күләмен, шулай ук айлык өстәмәләр һәм түләүләр күләме күтәрелгәндә (индексацияләгәндә) бер сумга кадәр артырга тиеш

әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау җирле бюджетта тиешле финанс елына каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге карарның күчермәсен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмле Казаклар Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

5. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге Башлыгы Г.Г. Нәҗипов